ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТАТАР САРСАЗЫ
ТОРАК ПУНКТЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
КАРАР

13.11.2025 ел № 1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы торак
пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2025 елның 1 ноябрендәге 3 нче номерлы карары нигезендә, 2025 елның 13 ноябрендә үзган гражданнар җыенында түбәндәге сорау буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы:

"1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татар Сарсазы авылының Куйбышев, Елга, Урман урамнары буйлап юлларны ремонтлау (вак таш, асфальт валчыклары сатып алу, тигезләү), Татар Сарсазы авылындагы юлларны кардан чистарту,;

2) урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Татар Сарсазы авылында яктырткычларны алыштыру).?»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
- гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 54 кеше кертелде,
- гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 32 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 32 катнашучысы тавыш бирде;
«КАРШЫ " позициясе өчен 0 тавыш.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы:

"1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татар Сарсазы авылының Куйбышев, Елга, Урман урамнары буйлап юлларны ремонтлау (вак таш, асфальт валчыклары сатып алу, тигезләү), Татар Сарсазы авылындагы юлларны кардан чистарту,;

2) урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Татар Сарсазы авылында яктырткычларны алыштыру).?», дигән сорауны - танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Песәй авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы _____________ В.И.Мөхәммәтгалеев